# Күңелле балачак

Сибә кояш нурын безгә
Балкытып барыр юлны.
Килдек тормышны бизәргә
Тотынып кулга –кулны.

КУШЫМТА
Күңелле балачак
Без – замана баласы.
Алдагы тормышны бизәп,
Зур-зур юллар саласы.

2. Чулпан йолдыз юл күрсәтә
Яктырты безнең эзне.
Киләчәктә илебездә
Зур эшләр көтә безне.

3. Гаиләгә рәхмәтле без
Алар безгә зур терәк.
Балкысын уңышларыбыз
Бездән булыр ул бүләк.